**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 42-3** **«01»ноябрь 2024 ел**

ТР Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Болгар шәһәре»муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының « үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына (ТР Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 08 сентябрендәге 57-3 номерлы, 2022 елның 24 октябрендәге 20-1 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 21-3 номерлы, 2024 елның 02 июлендәге 39-1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта “13 323” саннарын “13 990” саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс - бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В. Мөхәммәтов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 01 ноябрендәге 42-3 номерлы карары редакциясендә)

“Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгын, депутатларны, жирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 7 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 29 663 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 26 527 |
| Депутат | 15 024 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзасы | 13 990 |